КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 апрель г.Казань № 332

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында «Хлебодаровка – Анины Салманы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында төбәк әһәмиятендәге «Хлебодаровка – Анины Салманы» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен юридик затлар милкендә (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) булган, кушымтада күрсәтелгән 45 702 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районындагы Салман

авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында «Хлебодаровка – Анины Салманы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 289 нчы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты нигезендә Татарстанның юл-транспорт идарәсенә 16:06:0000:59, 16:06:0000:37, 16:06:100902:80 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә һәм алына торган җир кишәрлекләре карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 8 апрель, 332 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 16:06:000000:59 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Салман авыл җирлеге, «Хлебодаровка» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы | 14 216 | «Восточная Земельная Компания» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 2. | 16:06:000000:37 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, «Хлебодаровский» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы | 31 292 | «Восточная Земельная Компания» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 3. | 16:06:100902:80 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Салман авыл җирлеге | 194 | “Кызыл Шәрык Агро” акционерлык җәмгыяте |
| Барлыгы | | | 45 702 | |

______________________